ЛЕНИНОГОРСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД ЛЕНИНОГОРСК
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЛЕНИНОГОРСК ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
ЛЕНИНОГОРСК
ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

16.03.2022 г.Лениногорск № 86

Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Советының 2013 елның 27 декабрендәге 121 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 6 декабрендәге 408-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 30 декабрендәге 476-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Лениногорск шәһәр Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Советының 2013 елның 27 декабрендәге 121 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

**а) 1 статьяны** түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«блокланган төзелеш йорты - башка торак йорт (башка торак йортлар) белән бер рәттә гомуми Ян стенасы (гомуми як стеналары) белән блокланган һәм җир кишәрлегенә аерым чыгу урыны булган торак йорт.»;

**б) 25 статьяның 2 өлешен** түбәндәге эчтәлекле 6 пункт белән тулыландырырга:

«6) капиталь төзелеш объектларына, шул исәптән Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 52 статьясындагы 11 өлешендә күрсәтелгән очракта, капиталь ремонт ясау.».

**в) 36 статьяда «Участок зурлыгы»** бүлекчәсен түбәндәге эчтәлектәге җөмлә белән тулыландырырга:

«Участокның минималь (1000 кв. м) һәм максималь күләме (1200 кв. м) яңа төзелә торган җир кишәрлекләре өчен билгеләнә.».

2. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәр Советының әлеге карарның 1 пунктындагы «В» пунктчасы 2021 елның 20 маеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны рәсми публикаторда, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш буенча комиссиясенә йөкләргә.

Лениногорск шәһәре
муниципаль берәмлеге Башлыгы,
Лениногорск шәһәре мэры Р.Г. Хөсәенов